ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2019 п.г.т.Алексеевское № 586

**2020 нче елга халыкка күрсәтелә торган**
**Алексеевск муниципаль районының**
**торак хезмәтләренә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 14 декабрендәге ПУ-746 номерлы Указы нигезендә,

**карар кылам**:

1. Халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр расларга:

- социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап тоткан өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме (1 нче кушымта).

2. Халыкка күрсәтелә торган торак _ хезмәт күрсәтүләренә 2020 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр тарифларны расларга:

- дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү).

3. «Татмедиа» АҖ филиалы «Заря» газетасы редакциясе (Тан) шушы карарны бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы сайтында бастырырга http: //alekseevskiy.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 27 декабрендәге
586 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме**

| № | Хезмәтнең исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Алексеевск шәһәр җирлеге | | Левашевский, Ялкын, Большетиганский, Лебедино Большие Поляны авыл җирлекләре | |
| | | | 01.01.-30.06. | 01.07.-31.12. | 01.01.-30.06. | 01.07.-31.12. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 2,77 | 2,87 | 2,77 | 2,87 |
| 2 | Авыл яны территориясен санитар карап тору һәм санитар чистарту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 1,72 | 1,80 | - | - |
| 3 | Торак биналарны ремонтлау һәм йорт тирәсен төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 3,0 | 3,1 | 3,0 | 3,1 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт:<br>- йорт эчендәге | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 1,50 | 1,56 | 1,50 | 1,56 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | санитар-техник челтәрләр -җылылык челтәрләре | | - | - | - | - |
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ җиһазларыңа техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 0,33 | 0,34 | 0,33 | 0,34 |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | 0,91 | 0,94 | 0,91 | 0,94 |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г. А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 27 декабрендәге
586 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен (наем өчен) түләү күләме**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтне үлчәү бердәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| Наем | аена торак урынның гомуми мәйданы 1 кв.м | 6,11 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г. А. Йосыпова**